РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2019 нчы елның 11нче ноябре 391№

2022 нче елда Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы территориясендә
урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми
милекне капиталь ремонтлау буенча төбәк
программасын тормышка ашыруның
кыска вакытлы планын раслау турында

2007 нче елның 21 нче июлендәге 185-ФЗ номерлы "Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында" Федераль законны тормышка ашыру, торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фондтан чараларның, Татарстан Республикасы бюджетының, Әлки муниципаль районы бюджетының максатчан һәм нәтиҗәле кулланылуын, шулай ук торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш кооперативлары яки идарә итү күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан сайлап алынган, әлеге Федераль закон нигезендә күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга юнәлдерелгән идарәче оешма тарафыннан башкарыла торган күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан сайлап алына торган күпфатирлы йортта башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларының эшчәнлеген контрольдә тоту максатларында, Әлки муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 нче елда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планын расларга.(Кушымта)

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Йосыпов И.В.

Расланган
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитеты Советы Карары
2019 нчы елның 11 нче ноябре 391 №

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2013 нче елның 31 нче декабрендәге 1146 номерлы Карары белән расланган региональ программаны 2022 нче елда тормышка ашыруның Кыска сроклы планы**

2017- 2019 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2013 нче елның 31 нче декабрендәге 1146 номерлы Карары белән расланган региональ программаны тормышка ашыруның Кыска сроклы әлеге планы(алга таба-кыска вакытлы план, төбәк программасы шуңа бәйле рәвештә) Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 нче елның 21 нче июлендәге 185-ФЗ номерлы "Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында" Федераль закон (алга таба-Федераль закон), 2013 нче елның 25 нче июнендәге 52-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында" Татарстан Республикасы законы нигезендә, Төбәк программасын тормышка ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау срокларын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча планлаштырылган хезмәт төрләрен һәм (яки) эшләрне ачыклау, дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен билгеләү, капиталь ремонт үткәрүгә муниципаль ярдәм күрсәтү максатларында эшләнде.

## II. Кыска сроклы планының төп максатлары һәм бурычлары

Кыска сроклы планының төп максатлары булып тора:

Татарстан Республикасында торак фондын саклау, торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;

гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру;

дәүләт ярдәме, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауга муниципаль ярдәм.

Кыска сроклы планының төп бурычлары булып тора:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

кыска вакытлы планны башкаручыларны сайлап алуның үтә күренмәле һәм ачык процедураларын эшләү һәм үтәү;

озак сроклы материаллар һәм ресурсларны саклау технологияләре кулланып капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрне һәм комплекслылыкны куллану.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру срогы-2022 нче ел.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру 12 гражданга гомуми мәйданы 312,7 кв.метр булган 1 күпфатирлы йортта имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

## III. Кыска сроклы планны үтәүдә катнашучы муниципаль берәмлекләр исемлеге

Кыска сроклы планны үтәүдә катнашучы Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре исемлеге мондый муниципаль берәмлекләр территориясендә булуны исәпкә алып формалаштырылган:

а) Федераль законның 14 нче статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлгән;

б) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы (еллык) муниципаль планнары Дәүләт торак күзәтчелеге органнары белән расланган һәм килештерелгән.

Кыска сроклы планны тормышка ашыруда Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авыл җирлеге , Базарлы Матак авылы катнаша.

IV. 2022 нче елда күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлау күләме

| т/б № | Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2020-2021ел | 2022ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | |
| 1. | Түбәне ремонтлау, шул исәптән вентиляциясез түбәне вентиляцияләнә торган түбә итеп үзгәртеп ябу, түбәгә чыгу җайланмасын урнаштыру | мең кв.метр | 0 | 0,305 |
| 2. | Йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су бүлү инженер системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән торак биналарда урнашкан җылыту элементларын ремонтлау яки алыштыру, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында, шул исәптән, механик, электр, санитар-техник җиһазларда да: | мең метр | 0 | 0 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | мең метр | 0 | 0 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 0 | 0 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | мең метр | 0 | 0 |
| 2.4. | су бүлү (китү) белән тәэмин итү | мең метр | 0 | 0 |
| 3. | Коммуналь хезмәтләр (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ бирү) өчен кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыру | данә | 0 | 0 |
| 4. | Ресурслардан файдалануны җайга салу белән идарә итү төеннәрен һәм узелларын урнаштыру | данә | 0 | 0 |
| 5. | Файдалану өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын алыштыру | данә | 0 | 0 |
| 6. | Лифт шахталарын ремонтлау | данә | 0 | 0 |
| 7. | Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә караган подвал бүлмәләрен ремонтлау | мең кв.метр | 0 | 0 |
| 8. | Фасадны җылыту һәм ремонтлау | мең кв.метр | 0 | 0 |
| 9. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | мең кв.метр | 0 | 0 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 10. | Күпфатирлы йортка энергетика тикшерүләре үткәрү | данә | 0 | 0 |
| 11. | Күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | данә | 0 | 0 |
| 12. | Ремонт подъездов в многоквартирном доме | мең кв.метр | 0 | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13. | Күпфатирлы йортның янгынга каршы саклау системасын ремонтлау | мең кв.метр | 0 | 0 |
| 14. | Төзелеш контролен тормышка ашыру | данә | 0 | 1 |
| 15. | Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | данә | 0 | 1 |
| 16. | Капиталь ремонт үткәрү 2022 нче ел планлаштырылган күпфатирлы йортларның проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү һәм эшләү | данә | | 1 |

Күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләме 2 нче Кушымтада китерелгән.

## V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) җирле бюджетлар акчалары, ТСЖ, ЖК, ТТК яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яки күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тора.

Кыска сроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме 1106893 сум тәшкил итәчәк.

2022 нче елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме.

| т/б № | Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Эш күләме | |
|---|---|---|---|
| | | 2020-2021ел | 2022ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Түбәне ремонтлау, шул исәптән вентиляциясез түбәне вентиляцияләнә торган түбә итеп үзгәртеп ябу, түбәгә чыгу җайланмасын урнаштыру | 0 | 1028491 |
| 2. | Йорт эчендәге электр, җылыяык, газ, су белән тәэмин итү, су бүлү инженер системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән торак биналарда урнашкан җылыту элементларын ремонтлау яки алыштыру, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында, шул исәптән, механик, электр, санитар-техник җиһазларда да: | 0 | 0 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | 0 | 0 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | 0 | 0 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | 0 | 0 |
| 2.4. | су бүлү (китү) белән тәэмин итү | 0 | 0 |
| 3. | Коммуналь хезмәтләр (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ бирү) өчен кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыру | 0 | 0 |
| 4. | Ресурслардан файдалануны җайга салу белән идарә итү төеннәрен һәм узелларын урнаштыру | 0 | 0 |
| 5. | Файдалану өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын алыштыру | 0 | 0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Лифт шахталарын ремонтлау | 0 | 0 |
| 7. | Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә караган подвал бүлмәләрен ремонтлау | 0 | 0 |
| 8. | Фасадны җылыту һәм ремонтлау | 0 | 0 |
| 9. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | 0 | 0 |
| | | | |
| 10. | Күпфатирлы йортка энергетика тикшерүләре үткәрү | 0 | 0 |
| 11. | Күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | 0 | 0 |
| 12. | Ремонт подъездов в многоквартирном доме | 0 | 0 |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 13. | Күпфатирлы йортның янгынга каршы саклау системасын ремонтлау | 0 | 0 |
| 14 | Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | | |
| 15 | 2017-2019 елларда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларның проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү һәм эшләү. | | 67334 |
| 16. | Төзелеш контролен тормышка ашыру | 0 | 11068 |
| 15. | Ресурсларны куллануны җайга салу төеннәрен урнаштыру (бары тик ТСЖ, ТК, ТТК яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яисә күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре акчалары хисабына гына, шул ук вакытта ресурсларны куллануны җайга салу төеннәрен урнаштыруны финанслау 2014 елдан 2019 елга кадәр кыска сроклы планнар һәм төзелгән шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла) | 0 | 0 |
| 16. | Барлыгы* | | 1106893 |

Капиталь ремонт үткәрү бәясен күрсәтеп, күпфатирлы йортларның исемлеге кыска сроклы планга 1 нче кушымтада китерелгән.

1 нче һәм 2 нче кушымталарда кыска сроклы планны үтәү буенча планлаштырылган күрсәткечләр.

## VI. Хезмәтләр һәм (яки) капиталь ремонт эшләренең иң чик бәясе

2022 нче елга күпфатирлы йортларда биналарның гомуми мәйданының 1 кв. метрына исәпләгәндә хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яки) капиталь ремонт эшләренең чик бәясе 3539 сум тәшкил итә. (2 нче Кушымта)

Шул ук вакытта хәзерге кыска сроклы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясенең эш төрләре буенча Күләме Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы (алга таба – Министрлык) белән раслана.

Әлеге бүлектә каралган хезмәтләрнең һәм (яки) капиталь ремонт эшләренең чик бәясеннән артып китү, шулай ук хезмәт күрсәтүләргә һәм (яки) эшләргә кыска сроклы планда каралмаган түләү капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән артыграк түләнә торган күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре хисабына гамәлгә ашырыла.

## VII. Кыска сроклы планны тормышка ашыру механизмы.

Әлеге кыска сроклы планны тормышка ашыру Министрлык, коммерцияле булмаган “Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы Фонды” оешмасы (алга таба – региональ оператор), Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, ТСЖ, ТК, ТТК, идарә оешмалары (алга

таба – УО), биналарның милекчеләре, подрядчы оешмалар (алга таба – кыска сроклы планны үтәүчеләр) тарафыннан тормышка ашырыла.

Министрлык:

кыска сроклы планны үтәүчеләр белән үзара хезмәттәшлекне, кыска сроклы план чараларын гамәлгә ашырганда аларның эшчәнлеген координацияләүне һәм тикшереп торуны оештыра;

региональ программаны тормышка ашыруның кыска сроклы (еллык) муниципаль планнарын карый һәм муниципаль берәмлекләр тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен тикшерә;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауны үз вакытында үткәрүне тәэмин итү максатларында төбәк операторы белән хезмәттәшлек итә;

җирле үзидарә органнары тапшырган хисапларны анализлау нигезендә финанс ярдәме күрсәтүнең кыска сроклы планын гамәлгә ашыру һәм шартларын үтәү мониторингын гамәлгә ашыра;

үзенең сайтында кыска вакытлы планга кергән күпфатирлы йортларның исемлеген урнаштыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен, шул исәптән тиешле тәртипне раслау юлы белән дә, подрядчы оешмаларны сайлап алу процедурасында катнаша;

үз компетенциясе кысаларында кыска вакытлы план чараларын гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны оештыра.

Төбәк операторы:

дефектлы ведомстволар әзерләү, шулай ук түләү документларын формалаштыру һәм капиталь ремонт өчен биналарның милекчеләреннән региональ оператор хисабына взнослар керүне тәэмин итү буенча УО белән килешүләр төзи;

проект документларын әзерләүгә, техник заказчы функцияләрен тормышка ашыруга, төзелеш контролен тормышка ашыруга шартнамәләр төзи, шулай ук күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләр һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүгә подрядчы шартнамәләре, күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итүнең тиешле акты имзаланганнан соң, биш елдан да ким булмаган вакыт эчендә күрсәтелгән хезмәтләргә һәм (яки) башкарылган эшләргә гарантия срогын билгеләүне, шулай ук подрядчы оешмаларның ачыкланган бозуларны тиешле срокта, үз хисабына һәм үз көчләре белән бетерү бурычын күздә тота;

үзенең рәсми сайтында күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең һәм региональ операторның Торак кодексы, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәү белән бәйле барлыкка килгән хокуклары һәм бурычлары турында, капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында мәгълүмат, шулай ук исемлеге Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2015 нче елның 11нче ноябрендәге 803/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән башка белешмәләр урнаштыра;

законнарда билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен, подрядчы оешмаларны сайлап алуны гамәлгә ашыра;

күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау, проект документларын эшләү, закон таләпләре нигезендә төзелеш контроле буенча хезмәт күрсәтүләрне һәм (яки) эшләрне кыска сроклы планда каралган күләмдә һәм срокларда финанслауны гамәлгә ашыра;

башкарылган эшләр өчен подрядчы оешмаларга, идарәче оешма, муниципаль берәмлек, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе, төзелеш контролен тормышка ашыручы оешма, биналарның милекчеләре вәкиле белән килештерелгән КС-3, КС-2 формалары нигезендә түли;

күпфатирлы йортта биналарның һәр милекчесе буенча акча керүне исәпкә алуны гамәлгә ашыра;

кыска сроклы планны гамәлгә ашыру кысаларында министрлыкка соратып алына торган документларны һәм мәгълүматларны тапшыра;

законнарда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе:

капиталь ремонт эшләрен башкаруның дефектлы ведомостьларын һәм күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү буенча муниципаль адреслы программаларны, программаларны тормышка ашыруның кыска сроклы планнарын килештерә;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу процедурасында катнаша, капиталь ремонт үткәрү өчен квалификацияле һәм намуслы подрядчы оешмаларны җәлеп итүне контрольдә тота;

күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясауның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тота;

башкарылган эшләр һәм (яки) хезмәтләр актларын килештерә;

капиталь ремонт тәмамланган объектны файдалануга кабул итүдә катнаша;

подряд килешүләре реестрын алып бара;

капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлап алу турында милекчеләр җыелышларының беркетмәләрен исәпкә ала;

соратып алына торган документларны һәм белешмәләрне кыска сроклы планны гамәлгә ашыру кысаларында Министрлыкка һәм башка кыска сроклы планны башкаручыларга тапшыра.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары:

региональ программаны тормышка ашыруның кыска сроклы (еллык) муниципаль планнарын формалаштыралар һәм Министрлыкка җибәрәләр;

Министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен раслаучы норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм башка документлар тапшыралар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

җирле бюджет акчаларын федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм торак законнары нигезендә әлеге кыска сроклы планда билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга күчерәләр;

Региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне техник заказчы функцияләрен гамәлгә ашыралар;

башкарылган эшләр актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен расланган чыгымнар сметасында каралмаган акчалардан тыш, шулай ук ул арткан очракта да, килештерәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тоталар;

Министрлык билгеләгән тәртиптә тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска сроклы планны (шул исәптән күпфатирлы йортларда торак һәм торак булмаган биналар мәйданнары буенча мәгълүматлар) гамәлгә ашыру максатларында актуаль мәгълүматлар базасын барлыкка китерәләр һәм хәлдә ярдәм итәләр;

Министрлыкка һәм кыска сроклы планның башка башкаручыларына Фондка хисап формалаштыру өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр тапшыралар.

ТСЖ, ЖСК, ЖК, УО:

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә дефект исемлекләрен, башкарылган эшләр һәм (яки) хезмәтләр күрсәтү актларын килештерәләр;

региональ оператор белән түләү документларын формалаштыруга һәм капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча милекчеләрнең ай саен исәпләнүен һәм түләүләрен региональ оператор счетына күчерүне тәэмин итүгә шартнамәләр (килешүләр) төзиләр;

проект документларын әзерләүне тәэмин итәләр;

Министрлык тарафыннан расланган тәртип нигезендә сайлап алуны оештыручы булып торалар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

торак милекчеләренә капиталь ремонт башлау вакыты, хезмәт күрсәтү һәм (яки) эш күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йорттагы гомуми милекне капиталь ремонтлауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәрне тәкъдим итәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау мәсьәләләре буенча милекчеләрнең җыелышларын оештыра;

капиталь ремонт объектларына керүне рөхсәт итәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тоталар, шулай ук капиталь ремонттан соң күп фатирлы йортларны файдалануга кабул итүдә, капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән катнашалар;

күпфатирлы йортны авариясез эксплуатацияләүнең һәм аңа керүче инженерлык системаларының билгеләнгән гарантия срогыннан ким булмаган күләмдә күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау буенча дефектлы ведомостьлар, проект-смета һәм башкарма документацияне саклыйлар.

Бина хуҗалары:

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә карата җитешсезлек исемлекләрен килештерәләр;

күп фатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауны үз вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тотуда, шулай ук аларны капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән файдалануга алуда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча Кыска сроклы план һәм подряд килешүе белән билгеләнгән вакыт эчендә эшләрне башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формалары буенча башкарылган эшләр актларын формалаштыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күп фатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җаваплылык тоталар;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешмалар:

проект документларын, шул исәптән сметаны әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү вакытында төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

объектны кулланышка кабул итүдә катнашалар, объектны кабул итү актын килештерәләр;

күп фатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җаваплы;

проект оешмасыннан проект-смета документларын кабул итәләр;

күпфатирлы йортта күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне кабул итү актына кул куйганнан соң 10 көн эчендә әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затка күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән, проект, смета документлары, хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) капиталь ремонт буенча эшләр башкару турындагы шартнамәләрнең күчермәләрен) һәм финанс документларыннан тыш, капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документларны тапшыралар;

техник заказчының законнарда каралган башка функцияләрен гамәлгә ашыралар.

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы массакүләм мәгълүмат чараларында Кыска сроклы план чараларын гамәлгә ашыру барышын даими яктыртуны гамәлгә ашыра.

Кыска сроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында тормышка ашырыла.

## VIII. Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкару һәм (яки) хезмәтләр күрсәтү өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Подрядчы оешмалар Региональ оператор, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары, муниципаль бюджет, казна учреждениеләре тарафыннан Министрлык тарафыннан расланган тәртип нигезендә сайлап алына.

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы й гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыру планына кертелгән күпфатирлы йортлар реестры

| № | КФЙ адресы | капиталь ремонтның бәясе | шул исәптән | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | СМРбәясе | күпфатирлы йортларны инвентризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | | 2020 нче елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонт бәясен дөрес итеп билгеләү | 2021 нче елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонт бәясен дөрес итеп билгеләү | 2022 нче елга планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонт бәясен дөрес итеп билгеләү | Төзелеш контролен тормышка ашыру |
| | | сум | сум | берәмлек | сум | сум | сум | сум | сум |
| 2022 г | | | | | | | | | |
| 1 | Базарлы Матак авылы,Совет ур. 3й. | 1106893 | 1028491 | 0 | 0 | 0 | 0 | 67334 | 11068 |